СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2020 г. Заинск №193

**«Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башкарма комитеты баш хисапчысы һәм хисапчысы хезмәтенә түләүне оештыру турында нигезләмә хакында» 2019 елның 20 маендагы 153 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башкарма комитеты баш хисапчысы һәм хисапчысы хезмәтенә түләүне оештыру турында нигезләмә хакында" 2019 елның 20 маендагы 153 номерлы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәр Советы карары белән расланган муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Башкарма комитеты баш хисапчысы һәм хисапчысы хезмәтенә түләүне оештыру турында нигезләмәнең 2.2 пунктына үзгәреш кертергә һәм "баш хисапчы" һәм "хисапчы" юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфа | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кешесе булган | 3,5 меңнән артык кешесе булган |
| Баш хисапчы | 16 171 сум | 17 510 сум |
| Хисапчы | - | 14 935 сум |

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**